КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 май г.Казань № 720

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2025 ел, 11 июнь, 421 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2025 ел, 11 июнь, 421 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «3 570 кв.метр» сүзләрен «2 193 кв.метр» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының»Территорияне планлаштыру документларын раслау турында» 2023 елның 04 апрелендәге 414 номерлы карары белән расланган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында «Казан - Ульяновск - Иске Барыш - Кама Тамагы» - Кече Бортас автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча документацияне раслау турында» 2023 елның 04 апрелендәге 414 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 2025 елның 24 декабрендәге 648 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 10 көн эчендә түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин